**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Алексеевск районының Ромодан авылы;
Апас районының Карамасар авылы;
Апас районының Иске Әнәле авылы;
Кайбыч районының Надеждино авылы;
Сарман районының Кәүҗияк авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Әтнә районының Олы Әтнә авылындагы Гагарин урамы;
Зәй шәһәренең Ульянов урамы;
Саба районының Кече Кибәче авылындагы Маркс урамы;
Саба районының Лесхоз поселогындагы Детсад урамы;
Спас районының Красный Вал авылындагы Яңа урам;
Тәтеш шәһәренең Базовая урамы.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 28 гыйнварындагы ПУ-70 номерлы Указының «а» пунктчасы, «б» пунктчасының икенче, өченче, дүртенче һәм алтынчы абзацлары;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан

Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 4 февралендәге ПУ-89 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2015 ел, 08 апрель
№ ПУ-377